| | |
|---|---|
| ГЛАВА ЛЕШЕВ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛӘШӘҮ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13 ноябрь 2025 ел № 7

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Дүсем авылы өлешендә 2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 маддәсе, 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы законының 35 статьясы нигезендә, Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге Уставының 18.1 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Ләшәү Тамак авылы, Механизаторлар урамы, 1а йорты адресы буенча урнашкан Мәдәният йорты бинасында 2025 нче елның 20 нче ноябренә 11 сәгатьтә Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Дүсем авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан кала, Дүсем авылы Ләшәү Тамак авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2026 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1) Дүсем авылында "Беларус 82.1" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү);

2) Дүсем авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар алу);

3) юл кырыен чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, йөртүче хезмәтенә түләү);

4). Дүсем авылы, Совет урамы, авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш ташу);

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгының «Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлегенең Дүсем торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында " 2025 елның 07 ноябрендәге 3 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Ләшәү Тамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында, http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы

Ләшәү Тамак авыл җирлеге башлыгы: И.З.Хабибуллин